МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ
И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН
ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ
ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

27.10.2014 № 590

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2014 елның 17 декабрендә теркәлде, №2564

"Фашистлар концлагерьларының, гетто
һәм Икенче Бөтендөнья сугышы чорында фашистлар
һәм аларның союзниклары тарафыннан
оештырылган башка мәҗбүри тоту урыннарының
элеккеге балигъ булмаган тоткыннарына
ташламаларга хокук турында таныклык
бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентын раслау хакында"
05.06.2012 ел, №383 Татарстан Республикасы Хезмәт,
эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы
боерыгына үзгәрешләр кертү турында

"Фашистлар концлагерьларының, гетто һәм Икенче Бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары тарафыннан оештырылган башка мәҗбүри тоту урыннарының элеккеге балигъ булмаган тоткыннары өчен билгеләнгән социаль ярдәм чараларына хокук турында таныклыклар рәсмиләштерү, бирү һәм учетка кую тәртибен раслау турында" 04.09.2013 ел, №445н Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы үз көченә керүгә бәйле рәвештә, боерык бирәм:

1. "Фашистлар концлагерьларының, гетто һәм Икенче Бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары тарафыннан оештырылган башка мәҗбүри тоту урыннарының элеккеге балигъ булмаган тоткыннарына ташламаларга хокук турында таныклык бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында" 05.06.2012 ел, №383 Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль

яклау министрлыгы боерыгына (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Фашистлар концлагерьларының, гетто һәм Икенче Бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары тарафыннан оештырылган башка мәҗбүри тоту урыннарының элеккеге балигъ булмаган тоткыннары өчен билгеләнгән социаль ярдәм чараларына хокук турында таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында”;

боерык преамбуласын түбәндәге редакциялә бәян итәргә:

“Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 27 июль, 2010 ел, №210-ФЗ Федераль законны үтәү йөзеннән, боерык бирәм:”;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.Фашистлар концлагерьларының, гетто һәм Икенче Бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары тарафыннан оештырылган башка мәҗбүри тоту урыннарының элеккеге балигъ булмаган тоткыннары өчен билгеләнгән социаль ярдәм чараларына хокук турында таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (кушымта итеп бирелә) расларга.”;

Әлеге Боерык белән расланган Фашистлар концлагерьларының, гетто һәм Икенче Бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары тарафыннан оештырылган башка мәҗбүри тоту урыннарының элеккеге балигъ булмаган тоткыннарына ташламаларга хокук турында таныклык бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы
Хезмәт, эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау
министрлыгының
05.06.2012 ел, №383 боерыгы
белән расланды

**Фашистлар концлагерьларының, гетто һәм Икенче Бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары тарафыннан оештырылган башка мәҗбүри тоту урыннарының элеккеге балигъ булмаган тоткыннары өчен билгеләнгән социаль ярдәм чараларына хокук турында таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Фашистлар концлагерьларының, гетто һәм Икенче Бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары тарафыннан оештырылган башка мәҗбүри тоту урыннарының элеккеге балигъ булмаган тоткыннары өчен билгеләнгән социаль ярдәм чараларына хокук турында таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең бу Административ регламенты (алга таба – Регламент) фашистлар концлагерьларының, гетто һәм Икенче Бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары тарафыннан оештырылган башка мәҗбүри тоту урыннарының элеккеге балигъ булмаган тоткыннары өчен билгеләнгән социаль ярдәм чараларына хокук турында таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтү) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте алучылар – Икенче Бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары тарафыннан оештырылган концлагерьларда, гетто, башка мәҗбүри тоту урыннарының элеккеге балигъ булмаган тоткыннары.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә мөрәҗәгать итүчеләр булып дәүләт хезмәте алучылар яки аларның законлы вәкилләре (законнар нигезендә күздә тотылган очракларда) яисә дәүләт хезмәте алучылар тарафыннан билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә эш итүгә вәкаләт бирелгән зат (алга таба – мөрәҗәгать итүче) тора.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының дәүләт хезмәте күрсәтүне алучының яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районы яки шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлек) (алга таба – Идарә (бүлек) аша күрсәтелә.

1.3.1. Идарәнең (бүлек) урнашу урыны, белешмәләр алу өчен телефоннары, электрон почта адресы бу Регламентка белешмә-кушымтада күрсәтелгән.

Идарәнең (бүлек) эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән тыш, көн саен, Идарәнең (бүлек) эчке тәртип кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән эш сәгатьләрендә.

1.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының, Идарәләрнең (бүлек) гражданнар белән эшләү өчен иҗтимагый кабул итү бүлмәләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматтан торган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аша;

2) “Интернет” челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында: http://mtsz.tatar.ru;

Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http:// uslugi.tatar.ru/);

Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтүнең бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Идарәгә (бүлек), Министрлыкка (шәхсән яки телефон аша) телдән мөрәҗәгать иткәндә;

4) Идарәгә (бүлек), Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге законнар һәм норматив-хокукый актлар нигезендә хәл ителә:

“Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 27.07.2010, № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ Федераль закон) (РФ законнар җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Электрон имза турында” 6 апрель, 2011е , №63-ФЗ Федераль закон (алга таба – №63-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2011, №15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Персональ мәгълүматлар турында” 27 июль, 2006 ел, №152-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2006, №31 (1 б.), 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Фашистлар концлагерьларының, гетто һәм Икенче Бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары тарафыннан оештырылган башка мәҗбүри тоту урыннарының элеккеге балигъ булмаган тоткыннары өчен билгеләнгән социаль ярдәм чараларына хокук турында таныклык хакында” 29.05.2013 ел, №452 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары;

“Фашистлар концлагерьларының, гетто һәм Икенче Бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары тарафыннан оештырылган башка мәҗбүри тоту урыннарының элеккеге балигъ булмаган тоткыннары өчен билгеләнгән социаль ярдәм чараларына хокук турында таныклыклар рәсмиләштерү, бирү һәм учетка алу тәртибен раслау хакында” 4 сентябрь, 2013 ел, №445н Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән расланган Фашистлар концлагерьларының, гетто һәм Икенче Бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары тарафыннан оештырылган башка мәҗбүри тоту урыннарының элеккеге балигъ булмаган тоткыннары өчен билгеләнгән социаль ярдәм чараларына хокук турында таныклыклар рәсмиләштерү, бирү һәм учетка алу тәртибе (алга таба – Тәртип) (“Российская газета”, №249, 06.11.2013);

“Икенче Бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары тарафыннан оештырылган концлагерьларның, гетто башка мәҗбүри тоту урыннарының элеккеге балигъ булмаган тоткыннарына ташламалар бирү тәртибе һәм шартлары турында” аңлатманы раслау хакында” 7 июль, 1999 ел, №20 Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль үсеш министрлыгы карары белән расланган Икенче Бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары тарафыннан оештырылган концлагерьларның, гетто башка мәҗбүри тоту урыннарының элеккеге балигъ булмаган тоткыннарына ташламалар бирү тәртибе һәм шартлары турында

аңлатма (“Российская газета”, 30.08.1999 ел, №168, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре” 15.08.2007, № 388 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрдән чыгып).

1.5. Бу Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза төшенчәсе дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросны аңлата (27.07.2010 ел, №210-ФЗ Федераль законның 2 статьясындагы 1 пункты). Гаризаның тәкъдим ителә торган формасы бу Регламентка 1 кушымтада китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандарт таләбе атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1.Дәүләт хезмәте атамасы | Фашистлар концлагерьларының, гетто һәм Икенче Бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары тарафыннан оештырылган башка мәҗбүри тоту урыннарының элеккеге балигъ булмаган тоткыннары өчен билгеләнгән социаль ярдәм чараларына хокук турында таныклык (таныклык дубликаты) бирү | Тәртипнең 1 п., 7 п. |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы атамасы | Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының дәүләт хезмәте алучының яшәү урыны буенча Ттатарстан Республикасы муниципаль районындагы яки шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлек) аша | Тәртипнең 2 п. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Таныклык (таныклык дубликаты) бирү, таныклык (таныклык дубликаты)бирүдән баш тарту | Тәртипнең 1 п., 7 п. |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгыннан чыгып | Таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында карар бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар белән гариза теркәүгә алынганнан соң ундүрт эш көне эчендә кабул ителә.<br>Таныклык бирү мөрәҗәгать итүче таныклык (таныклык дубликаты) алырга килгән көнне хәл ителә. | Тәртипнең 4 п. |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә | Таныклык алу өчен:<br>1. №1 кушымта нигезендәге форма буенча гариза.<br>2. Шәхесне раслаучы документ күчермәсе.<br>3. Фашизмның балигъ булмаган элеккеге тоткынының Икенче Бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары тарафыннан | Тәртипнең 3 п., 7 п. |

| | | |
|---|---|---|
| мөрәҗәгать итүче тапшырырга тиешле кирәкле документларның тулы исемлеге, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны күрсәтү тәртибе | Германия һәм аның белән союздаш илләр территорияләрендә, шулай ук элеккеге СССР һәм Европа илләренең оккупацияләнгән территорияләрендә оештырылган концлагерьларда, гетто һәм башка мәҗбүри тоту урыннарында булуын раслаучы сугыш чоры документлары яки кирәкле мәгълүматлардан торган белешмәләр һәм архив учреждениеләренең, башка учреждениеләрнең документлары.<br>4. Дәүләт хезмәте алучының 3х4 үлчәмендәге фотосурәте.<br>Таныклык дубликаты алу өчен:<br>1. №1 кушымта нигезендәге форма буенча гариза.<br>2. Дәүләт хезмәте алучының 3х4 үлчәмендәге фотосурәте.<br>Элек бирелгән таныклык яраксызга әйләнгән очракта яраксызга әйләнгән таныклык өстәмә рәвештә тапшырыла.<br>Дәүләт хезмәте алучыларның законлы вәкилләре (законнарда күздә тотылган очракларда) яки дәүләт хезмәте алучылар тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар дәүләт хезмәте алучы мәнфәгатьләреннән чыгып эш итүгә вәкаләтләрен раслаган документларны өстәмә рәвештә тапшыра.<br>Мөрәҗәгать итүче документлар һәм белешмәләрне архив учреждениеләреннән турыдан-туры ала, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон формада.<br>Документлар күчермәләре, Россия Федерациясе законнары нигезендә расланмаган очракта, төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Идарә (бүлек) белгече тарафыннан раслана.<br>Гаризаны почта аша җибәргәндә, аңа кушып бирелергә тиешле документлар күчермәләре (шәхесне раслаучы документ | |

| | | |
|---|---|---|
| | күчермәсеннән тыш) Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә расланган булырга тиеш. | |
| 2.6.Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булып, мөрәҗәгать итүче тапшыруга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны күрсәтү тәртибе; документларны үз карамагында тоткан дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма атамасы | Әлеге категориягә кертелергә мөмкин булган документлар тапшыру таләп ителми. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив-хокукый актларда күздә тотылган очракларда килештерергә тиешле (дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы хәл итә) дәүләт хакимияте органнары исемлеге | Килештерү таләп ителми. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | Бу Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән зат мөрәҗәгать иткәндә.<br>Бу регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегеннән ниндидер бер документны тапшырмаганда.<br>Мөрәҗәгать итүче яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итмәгәндә.<br>Документларда билгеләнгән төстә расланмаган бозу-сызулар, | Тәртипнең 2 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | төзәтүләр булганда. Идарәгә (бүлек) №63-ФЗ Федераль закон һәм №210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (расланмаган) электрон документлар рәвешендәге гариза һәм документлар (документлар күчермәләре) тапшырганда. | |
| 2.9.Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торуга нигезләр билгеләнмәгән. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигезләр: мөрәҗәгать итүче тапшырган документларда дәүләт хезмәте алучының балигъ булмаган яшендә Икенче Бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары тарафыннан Германия һәм аның союздаш илләре территорияләрендә, шулай ук оккупацияләнгән элеккеге СССР һәм Европа илләре территорияләрендә оештырылган концлагерьларда, гетто, башка мәҗбүри тоту урыннарында булганлыгын раслаган документлар булмаганда. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләргә түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12.Дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос тапшырганда һәм мондый | Мөрәҗәгать итүченең кабул ителүне (хезмәт күрсәтелү) көтүенең максималь срогы 15 минуттан артмаска тиеш. | |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Дәүләт хезмәте алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросын теркәү срогы | Гариза кергән көнне. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм кабул итү урынына, мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиаль мәгълүмат урнаштыруга карата таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү тиешле күрсәткечләр белән тәэмин ителгән бүлмәләрдә хәл ителә.<br>Дәүләт хезмәте алучыларны кабул итү бу максатлар өчен махсус билгеләнелгән урыннарда хәл ителә. Кабул итү урыннары тәэмин ителгән:<br>Янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы;<br>документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар;<br>мәгълүмати стендлар белән. | |
| 2.15.Дәүләт хезмәтенең дәүләт хезмәте алучылар өчен мөмкинлеге һәм сыйфат күрсәткечләре | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып тора:<br>документларны кабул итү һәм карап тикшерү срокларын үтәү;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу срогын үтәү;<br>белгечләр тарафыннан бу Регламентны бозу очракларының (нигезле шикаятьләр) булмавы.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең дәүләт хезмәте алучылар өчен мөмкинлеге күрсәткечләре булып тора:<br>Идарә (бүлек) бинасының җәмәгать транспорты йөри торган зонада урнашкан булуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документларны кабул итү өчен бүлмәләрнең кирәкле санда булуы;<br>мәгълүмати стендларда, “Интернет” челтәрендәге мәгълүмати ресурсларда, Министрлыкның рәсми сайтында, Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр | |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәтүнең бердәм порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүматның булуы.<br>электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза тапшыру мөмкинлеге. | |
| 2.16. Электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Гариза һәм документлар (документлар күчермәләре) Идарәгә (бүлек) №63-ФЗ Федераль закон һәм №210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин. | Тәртипнең 3 п., 7 п. |

**3. Административ процедуралар (гамәлләр) составы, аларны үтәү эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон рәвештә административ процедураларны (гамәлләр) үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күп функцияле үзәкләрдә административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре**

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләрнең эзлеклелегенең тасвирламасы

3.1.1. Таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү ягыннан;

2) гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) Министрлыкка таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында үтенечнамә җибәрү;

4) таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү;

5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелегенең блок-схемасы № 4 кушымтада китерелә.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү ягыннан.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультация алу өчен Идарәгә (бүлек) шәхсән үзе, телефон, электрон почта аша һәм (яки) почта аша хат белән язмача мөрәҗәгать итә. Консультацияләр алу өчен документлар күчермәләре электрон рәвештә Татарстан Республикасы

Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша тапшырылырга мөмкин.

Идарә( бүлек) белгече мөрәҗәгать итүчегә консультация бирә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге ягыннан һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү ягыннан.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм эчтәлеге ягыннан консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү ягыннан.

3.3. Гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче Идарәгә (бүлек) бу Регламентның 2.5 пункты нигезендә таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында гариза һәм аңа документларны кушып бирә.

Нотариуста расланган гариза һәм документлар күчермәләре почта аша заказлы хат белән җибәрелергә мөмкин.

Гариза һәм аңа кушып бирелә торган, Россия Федерациясе законнары нигезендә расланган документлар күчермәләре (шәхесне раслаучы документ күчермәсеннән тыш) почта аша заказлы хат белән җибәрелергә мөмкин.

Электрон почта аша җибәрелә торган гаризага һәм документларга № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон нигезендә имза салына һәм алар Идарәгә (бүлек) электрон туплагычларны куллану нигезендә тапшырыла.

Почта аша заказлы хат белән тапшырылган яки электрон рәвештә тапшырылган гариза һәм документлар (документлар күчермәләре) гомуми тәртиптә карап тикшерелә.

3.3.2. Идарә (бүлек) белгече хәл итә:

дәүләт хезмәте алучының законлы вәкиле яки вәкаләтле заты булып торган мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен тикшерә;

кирәкле барлык документларның булуын һәм аларның билгеләнгән таләпләргә (документларда чистарту, сызу-бозулар булмау, билгеләнгән тәртиптә расланмаган төзәтүләр булмау) туры килүен тикшерә;

Идарә (бүлек) белгече бу Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булганда, мөрәҗәгать итүчегә гаризаны теркәүдән баш тартуга нигезләрнең булуы турында җиткерә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен язмача күрсәтеп, документларны аңа кире кайтара.

Идарә (бүлек) белгече баш тартуга нигезләр булмаган очракта: гаризаны кабул итә һәм гаризаларны теркәү журналында (№2 кушымта) терки;

мөрәҗәгать итүчегә документларын кабул итү датасы, бирелгән керү номеры турында билге белән белдерү кәгазе тапшыра.

Электрон рәвештә тапшырылган гаризаны теркәү (кабул итү) бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән, № 63-ФЗ Федераль закон һәм №

210-ФЗ Федераль закон нигезендә имзаланган (расланган) документлар (документлар күчермәләре) кушып бирелмәгән очракта хәл ителми.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедуралар гариза кергән көнне хәл ителә.

Процедуралар нәтиҗәсе: документларны кабул итү, гаризаларны теркәү журналында теркәү язуы булдыру, мөрәҗәгать итүчегә белдерү кәгазе җибәрү яки документларын кире кайтару.

3.4. Министрлыкка таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында үтенечнамә җибәрү

3.4.1. Идарә (бүлек) белгече таныклык (таныклык дубликаты) рәсмиләштерү өчен кирәкле документларны берләштереп куя, таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында үтенечнамә проектын әзерли һәм аны Идарә (бүлек) җитәкчесенә имза салуга җибәрә.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура гариза кергән көнне хәл ителә.

Процедуралар нәтиҗәсе: таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында үтенечнамә проекты.

3.4.2. Идарә (бүлек) җитәкчесе таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында үтенечнамә проектына имза сала.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында үтенечнамәгә имза салу.

3.4.3. Идарә (бүлек) белгече Министрлыкка, бу Регламентның 2.5 пунктында күздә тотылган документлар күчермәләре белән бергә, таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында үтенечнамә җибәрә.

Процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: Министрлыкка, документлар күчермәләре белән бергә, таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында үтенечнамә җибәрү.

3.5. Таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында карар кабул итү.

3.5.1. Министрлыкның делопроизводство бүлеге белгече Идарәдән (бүлек) алынган, күчермәләре белән бергә, таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында үтенечнамәме “Электрон Хөкүмәт” Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документлар әйләнеше системасында терки һәм Министрлыкның социаль ярдәм чаралары методологиясе бүлегенә (алга таба – Бүлек) җибәрә.

Процедура документлар Идарәдән (бүлек) алынганнан соң бер эш көне эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлеккә документлар күчермәләре белән бергә җибәрелгән, таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында үтенечнамәне теркәү.

3.5.2. Бүлек белгече бу Регламентның 2.9 пунктында күздә тотылган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигезләрнең булуын тикшерә.

Бүлек белгече, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигезләр булмаган очракта, Идарәгә (бүлек), таныклык бланкы белән бергә, озату хаты проектын рәсмиләштерә.

Бүлек белгече, бу Регламентның 2.9 пунктында күздә тотылган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигезләр булган очракта, Идарәгә (бүлек) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту сәбәпләрен аңлатып, документлар күчермәләре белән бергә, таныклык (таныклык дубликаты) бирүдән баш тарту турында хат проекты рәсмиләштерә.

3.5.3. Бүлек белгече озату хаты проектын, таныклык (таныклык дубликаты) бланкы белән бергә, Идарәгә (бүлек) яки документлар белән бергә, Идарәгә (бүлек), таныклык (таныклык дубликаты) бирүдән баш тарту турында хат проектын министр урынбасарына имза салуга җибәрә.

Бу Регламентның 3.5.2, 3.5.3 пунктларында билгеләнелә торган процедуралар документлар Министрлыкка алынганнан соң ике эш көне эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: таныклык бланкы белән бергә, озату хаты проекты, документлар белән бергә, таныклык (таныклык дубликаты) бирүдән баш тарту турында хат проекты.

3.5.4. Министр урынбасары Идарәдә (бүлек), таныклык (таныклык дубликаты) бланкы белән бергә, озату хатын, яки, документлар күчермәләре белән бергә, таныклык (таныклык дубликаты) бирүдән баш тарту турында хатны имзалый.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: таныклык (таныклык дубликаты) бланкы белән бергә, озату хаты, яки, документлар күчермәләре белән бергә, таныклык (таныклык дубликаты) бирүдән баш тарту турында хат.

3.5.5. Министрлыкның делопроизводство бүлеге белгече “Электрон Хөкүмәт” Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документлар әйләнеше системасы аша, имзаланган озату хатын, яки, документлар күчермәләре белән бергә, таныклык (таныклык дубликаты) бирүдән баш тарту турында хатны терки һәм Идарәгә (бүлек) җибәрә һәм таныклык бланкын Идарәгә (бүлек) җибәрә.

Процедура алдагы процедуралар тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: Идарәгә (бүлек), таныклык (таныклык дубликаты) бланкы белән бергә имзаланган озату хатын, яки, документлар күчермәләре белән бергә, таныклык (таныклык дубликаты) бирүдән баш тарту турында имзаланган хатны җибәрү.

3.6. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

3.6.1. Идарә (бүлек) белгече Министрлык хаты нигезендә:

мөрәҗәгать итүчегә таныклык (таныклык дубликаты) бирүдән баш тарту турында карарны дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризада күрсәтелгән ысул (хат, телефон, смс-хәбәр, электрон почта аша) белән җиткерә;

таныклык (таныклык дубликаты) бланкын рәсмиләштерә;

дәүләт хезмәте алучының личное делосын булдыра (барлык документларны аерым папкага туплый).

Бу пунктта билгеләнелә торган процедуралар Министрлыктан таныклык бланкы яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында язмача белдерү кәгазе кергәннән соң бер эш көне эчендә хәл ителә.

Процедуралар нәтиҗәсе: таныклык (таныклык дубликаты) бланкын рәсмиләштерү, личное дело булдыру, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерү кәгазе җибәрү.

3.6.2. Идарә (бүлек) белгече рәсмиләштерелгән таныклык (таныклык дубликаты) бланкын Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрына (алга таба – министр) яки аны алыштыручы затка имза салуга җибәрә.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура таныклык бланкы рәсмиләштерелгәннән соң өч эш көне эчендә хәл ителә.

Процедуралар нәтиҗәсе: рәсмиләштерелгән таныклык (таныклык дубликаты) бланкын имза салуга җибәрү.

3.6.3. Министр яки аны алыштыручы зат рәсмиләштерелгән таныклык (таныклык дубликаты) бланкын имзалый, имзага мөхер суга, таныклыкны (таныклык дубликаты) Идарә (бүлек) белгеченә тапшыра.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура Министрлыкка рәсмиләштерелгән таныклык (таныклык дубликаты) бланкы алынган көнне хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: министр яки аны алыштыручы зат тарафыннан имзаланган, мөһер сугылган таныклык (таныклык дубликаты) бланкын Идарә (бүлек) белгеченә тапшыру.

3.6.4. Идарә (бүлек) белгече мөрәҗәгать итүчене таныклык (таныклык дубликаты) алырга чакыра (хат, телефон, смс-хәбәр, электрон почта аша).

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчене таныклык (таныклык дубликаты) алырга чакыру.

3.6.5. Идарә (бүлек) белгече:

таныклыклар бирү кенәгәсенә тиешенчә язып куя (№ 3 кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә таныклык (таныклык дубликаты) тапшыра.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче килгән көнне хәл ителә.

Процедуралар нәтиҗәсе: таныклыклар бирү кенәгәсенә тиешенчә язып кую, таныклык (таныклык дубликаты) тапшыру.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итү тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген үтәүгә агымдагы контрольлек Идарә

(бүлек) җитәкчесе тарафыннан Регламент нигезләмәләрен үтәүгә тикшерүләр үткәрү юлы белән хәл ителә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итүне Министрлыкның вазыйфаи затлары хәл итә. Контрольлекне хәл итүче вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык бүлекләре турында нигезләмәләрдә һәм вазыйфаи регламентларда билгеләнә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгы һәм сыйфатына контрольлек дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаятьләрдән торучы мөрәҗәгатьләрне карап тикшерүне, тикшерүләр үткәрүне, карарлар кабул итү һәм мөрәҗәгатькә җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлүенә контрольлек формалары булып:

делопроизводствоны алып баруга;

документларны карап тикшерү нәтиҗәләренең законнар (бу регламент) таләпләренә туры килүенә;

документларны кабул итү сроклары һәм тәртибе үтәлүгә;

дәүләт хезмәте күрсәтү срокларын, тәртибен һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен бирү тәртибен үтәүгә тикшерүләр үткәрү тора.

Тикшерүләр планлы (эш планнары нигезендә) һәм планнан тыш (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) үткәрелергә мөмкин.

4.3. Тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта гаепле дип танылган дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итү Идарәнең (бүлек) дәүләт хезмәте күрсәтүдәге эшчәнлегенең хәбәрдарлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләр) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу юлы белән хәл ителә.

## 5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының һәм дәүләт хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмау), шулай ук кабул иткән карарларына судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Идарә (бүлек) хезмәткәрләре гамәлләренә (гамәл кылмау) судка кадәр тәртиптә Идарә (бүлек) җитәкчесенә, Министрлык җитәкчесенә шикаять белдерүгә хокуклы.

Идарә (бүлек) җитәкчесе кабул иткән карарларга карата шикаятьләр Министрлыкка тиешле компетенциядәге министр урынбасары яки министр исеменә тапшырыла, министр урынбасары (министр) кабул иткән карарларга

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шикаять белдерелергә мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән, түбәндәге очракларда, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең запросын теркәү срогы бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе башка норматив-хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаганда;

дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

5.2. Шикаять язмача рәвештә кәгазьдә яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, Министрлыкның рәсми сайты (http:// mtsz.tatar.ru/), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталы: (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (вазыйфалар) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карап тикшерү срогы – аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының мөрәҗәгать итүчедән документларын кабул итеп алудан, яки хаталарны төзәтүдән баш тарту очрагында яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга шикаять белдерү очрагында – шикаятьне теркәүгә алганнан соң биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яки дәүләт хезмәткәре исеме;

2) гражданинның-физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүматлар, мөрәҗәгать итүче исеменнән эш йөртүче гражданин – юридик затның урнашу урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлар), электрон почта адресы (адреслар) (булганда) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) турында мәгълүматлар;

4) дәүләт хезмәте алучының дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) белән килешмәвенә дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән мөрәҗәгать итүче дәлилләрен раслаучы документлар яки аларның күчермәләре кушып бирелергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә кушып бирелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаятькә шикаятьне тапшырган дәүләт хезмәте алучы имза сала.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча бу Регламентның 5.1 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи зат түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан кабул ителгән карарны юкка чыгару рәвешендә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән хаталарны төзәтү, Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акча средстволарын мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Бу Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача һәм электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта шикаятьләрне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи зат материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

“Икенче Бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары тарафыннан оештырылган концлагерьларның, гетто һәм башка мәҗбүри тоту урыннарының элеккеге балигъ булмаган тоткыннары өчен билгеләнгән социаль ярдәм чараларына хокук турында таныклык бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына №1 кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы Идарәсенә (бүлек)

_______________________________

муниципаль районлагы (шәһәр)

ГАРИЗА

Мин, _________________________________________________________________,

(фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы)

түбәндәге адрес буенча яшим:

______________________________________________________________________

_________________________________________________________________________

(телефоны, адресы, электрон почта адресы)

шәхесен раслаучы документ төре

________________________ сериясе _____ № ______ бирелгән______________________

(кайчан, кем тарафыннан)

бирүегезне сорыйм_______________________________________________________

(Алучының Ф.И.О. (ышанычлы заты мөрәҗәгать итәкндә тутырыла)

һәм Икенче Бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары тарафыннан оештырылган фашистлар концлагерьларының, гетто һәм башка мәҗбүри тоту урыннарының элеккеге балигъ булмаган тоткыннарына билгеләнгән социаль ярдәм чараларына хокук турында таныклык (таныклык дубликаты) (кирәклесенең астына сызарга) бирүегезне сорыйм. Түбәндәге документларны кушып бирәм:

1. ___________________________________________________________________
2. ___________________________________________________________________
3. ___________________________________________________________________

Таныклыкны югалту (аны бозу) сәбәпләре (таныклык дубликатын сорап мөрәҗәгать иткәндә тутырыла)

________________________________________________________

“Персональ мәгълүматлар турында” 27 июль, 2006 ел. №152-ФЗ Федераль закон нигезендә, бу Гаризада күрсәтелгән персональ мәгълүматларны җыюга, эшкәртүгә, шул исәптән автоматлаштырылган рәвештә, саклауга һәм өченче затларга тапшыруга ризалык бирәм.Мәгълүматларның чынлыгын раслыйм.

Мәгълүмат алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында, ризамын.

________________________________________________________________

(язмача. телефон, смс-хәбәр, электрон почта аша)

"___" ___________ 20___ ел Мөрәҗәгать итүче имзасы _________________»;

Икенче Бөтендөнья сугышы чорында
фашистлар һәм аларның
союзниклары тарафыннан
оештырылган концлагерьларның,
гетто һәм башка мәҗбүри тоту
урыннарының элеккеге балигъ
булмаган тоткыннары өчен
билгеләнгән социаль ярдәм
чараларына хокук турында таныклык
бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
№2 кушымта

**Таныклыклар (таныклыклар дубликатлары) бирү турында гаризаларны теркәү**
**ЖУРНАЛЫ**

| № | Гаризаны кабул итү датасы | Мөрәҗәгать итүченең Ф.И.О. | Мөрәҗәгать итүче адресы | Таныклык төре | Таныклык бирү турында мәгълүматлар | Социаль яклау органы белгече имзасы | Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысулы (хәбәр итү датасы) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |

Икенче Бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары тарафыннан оештырылган концлагерьларның, гетто һәм башка мәҗбүри тоту урыннарының элеккеге балигъ булмаган тоткыннары өчен билгеләнгән социаль ярдәм чараларына хокук турында таныклык бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына №3 кушымта


**Таныклар бирү кенәгәсе**


| № п/п | Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме | Мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны адресы | Мөрәҗәгать итүченең паспорт мәгълүматлары | Таныклык сериясе һәм номеры | Таныклык бирү датасы | Мөрәҗәгать итүче имзасы | Искәрмәләр* |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

*дәүләт хезмәте алучының законлы вәкиле (законнар нигезендә күздә тотылган очракларда) яки дәүләт хезмәте алучының вәкаләтле заты мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте алучының мәнфәгатьләреннән чыгып эш итүгә вәкаләтләрне раслаган документ реквизитлары күрсәтелә.

Икенче Бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары тарафыннан оештырылган концлагерьларның, гетто һәм башка мәҗбүри тоту урыннарының элеккеге балигъ булмаган тоткыннары өчен билгеләнгән социаль ярдәм чараларына хокук турында таныклык бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына №4 кушымта

## Икенче Бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары тарафыннан оештырылган фашистлар концлагерьларының, гетто һәм башка мәҗбүри тоту урыннарының элеккеге балигъ булмаган тоткыннарына билгеләнгән социаль ярдәм чараларына хокук турында таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдәге гамәлләрнең эзлеклелегенең блок-схемасы




министр урынбасары
Хат проектларын имзалый (1көн)
Таныклык бланкы белән бергә, озату хатын яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хатны имзалау
Бүлек белгече
Таныклык бланкы белән бергә, озату хатын яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хатны Идарәгә (бүлек) жибәрә (1көн)
Таныклык бланкы белән бергә, озату хатын яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хатны Идарәгә (бүлек) жибәрү
Идарә (бүлек) белгече
Мөрәжәгать итүчегә таныклык (таныклык дубликаты) бирүдән баш тарту турында хәбәр итә, таныклык бланкы (таныклык дубликаты) рәсмиләштерә, дело булдыра, бланкны министрга яки аны алыштыручы затка имза салуга жибәрә( 4 көн)
рәсмиләштерелгән таныклык бланкы
Министр яки аны алыштыручы зат
Таныклык (таныклык дубликаты) бланкын рәсмиләштерә, мөхер суга (1 көн)
таныклык (таныклык дубликаты) бланкын имзалау
Мөрәжәгать итүчене таныклык (таныклык дубликаты) алырга чакыра (1 көн)
мөрәжәгать итүче килгән көнне таныклыкны бирә
таныклык (таныклык дубликаты)

Икенче Бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары тарафыннан оештырылган концлагерьларның, гетто һәм башка мәҗбүри тоту урыннарының элеккеге балигъ булмаган тоткыннары өчен билгеләнгән социаль ярдәм чараларына хокук турында таныклык бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмә)

**Икенче Бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары тарафыннан оештырылган концлагерьларның, гетто һәм башка мәҗбүри тоту урыннарының элеккеге балигъ булмаган тоткыннарына билгеләнгән социаль ярдәм чараларына хокук турында таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы органнар һәм вазыйфаи затлар турында мәгълүматлар**

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы яки шәһәр округларындагы Социаль яклау идарәләре (бүлекләр)

| Территориаль орган атамасы | Телефоны | Адресы |
|---|---|---|
| Әгерҗе муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85551)<br>2-10-86<br>2-26-39 | 422230, Әгерҗе ш.,<br>К.Маркс ур., 8 й.,<br>Agreez.Usz@tatar.ru |
| Азнакай муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85592)<br>7-25-10<br>7-14-25 | 423300, Азнакай,<br>Болгар ур., 9 й.<br>Usz.Azn@tatar.ru |
| Аксубай муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84344)<br>2-73-68<br>2-82-75 | 423060, Аксубай ш.т.б.,<br>Ленин ур., 8 й.<br>Usz.Aksubaevo@tatar.ru |
| Актаныш муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85552)<br>3-11-46<br>3-12-81 | 423740, Актаныш ав.,<br>Юбилей ур., 45 й.<br>Usz.Aktanysh@tatar.ru |
| Алексеевск муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84341)<br>2-41-40<br>2-46-46 | 422900, Алексеевск ш.т.б.,<br>Казаков ур., 8 й.<br>Usz.Alekseevsk@tatar.ru |
| Әлки муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84346)<br>2-08-90<br>2-08-91 | 422870, Базарлы Матак ав.,<br>Ленин ур., 9 й.<br>Usz.Alkeevo@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Әлмәт муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (8553) 32-45-50 | 423452, Әлмәт ш., 8 март ур.в 21а й. Usz.Almet@tatar.ru |
| Апас муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84376) 2-11-84 2-10-81 | 422350, Апас ав., Шоссе ур., 5 й. Usz.Apastovo@tatar.ru |
| Арча муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84366) 3-13-53 3-13-33 | 422000, Арча ш., Банк ур., 6в й. Usz.Arsk@tatar.ru |
| Әтнә муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84369) 2-16-60 2-16-57 | 422750, Олы Әтнә ав., Октябрь ур., 9 й. Usz.Atnya@tatar.ru |
| Баулы муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85569) 5-10-50 5-66-81 | 423930, Баулы ш., Җиңү мәйданы, 4 й. usz.bavly@tatar.ru |
| Балтач муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84368) 2-44-78 | 422250, Балтач ав., Һ.Такташ ур., 3а й. Usz.Baltasi@tatar.ru |
| Бөгелмә муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85594) 4-20-05 4-26-64 | 423230, Бөгелмә ш., Совет ур., 56 й. Usz.Bugulma@tatar.ru |
| Буа муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84374) 3-32-10 3-35-35 3-17-03 3-55-29 | 422430, Буа ш., Ленин ур., 52 й. Usz.Buinsk@tatar.ru |
| Югары Ослан муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84379) 2-17-57 2-13-01 | 422570, Югары Ослан ав., Медгородок ур. Usz.V-uslon@tatar.ru |
| Биектау муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84365) 2-32-43 | 422700, Биектау ст. т.юлчылар б., Профсоюз ур., 1а й. Usz.Vgora@tatar.ru |
| Чүпрәле муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84375) 2-38-07 2-31-52 | 422470, Иске Чүпрәле ав., Үзәк ур., 15 й. Drozh.Usz@tatar.ru |
| Алабуга муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85557) 7-51-55 7-87-86 | 423600, Алабуга ш., Спас ур., 5 й. Usz.Elabuga@tatar.ru |
| Зәй муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85558) 7-10-64 3-43-59 | 423520, Зәй ш., К рупская ур., 6 й. Usz.Zainsk@tatar.ru |
| Зеленодол муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84371) 5-58-80 5-79-90 | 422540, Зеленодол ш., Ленин ур., 25 й. Usz.Zeldol@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Кайбыч муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84370)<br>2-14-07<br>2-11-13 | 422330, Олы Кайбыч ав.,<br>Кояшлы бульвар, 7 й.<br>Usz.Kaybicy@tatar.ru |
| Кама тамагы муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84377)<br>2-15-57<br>2-12-45 | 422820, Кама Тамагы ш.т.б.,<br>К.Маркс ур., 2 й.<br>Usz.K-uste@tatar.ru |
| Кукмара муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84364)<br>2-84-76<br>2-64-65 | 422110, Кукмара ш.т.б.<br>Ворошилов ур., 44 й.<br>Usz.Kukmor@tatar.ru |
| Лаеш муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84378)<br>2-47-31<br>2-49-70 | 422610, Лаеш ш.,<br>Беренче Май ур., 35 й.<br>Osz.Laishevo@tatar.ru |
| Лениногорск муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85595)<br>5-07-51<br>6-02-26 | 423250, Лениногорск ш.,<br>Горький ур., 21 й.<br>Usz.Leninogorsk@tatar.ru |
| Мамадыш муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85563)<br>3-12-36 | 422190, Мамадыш ш.,<br>Совет ур., 10 й.<br>Usz.Mamadysh@tatar.ru |
| Менделеев муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85549)<br>2-23-00 | 423650, Менделеев ш.,<br>Бурмистров ур., 7а й.<br>Usz.Mendeleev@tatar.ru |
| Минзәлә муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85555)<br>3-26-59<br>3-19-77<br>3-14-52 | 423700, Минзәлә ш.,<br>Ленин ур., 80 й.<br>Usz.Menzelinsk@tatar.ru |
| Мөслим муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85556)<br>2-57-37 | 423970, Мөслим ав.,<br>Пушкин ур., 47 й.<br>Usz.Muslyumovo@tatar.ru |
| “Чаллы шәһәре” муниципаль берәмлегендә социаль яклау идарәсе | (8552)<br>34-48-48<br>58-71-52 | 423805, Чаллы ш.,<br>Х.Туфан проспекты, 23 й.<br>Usz.Chelny@tatar.ru |
| Түбән Кама муниципаль районында социаль яклау идарәсе | (8555)<br>45-39-20<br>45-43-86<br>45-43-89 | 423570, Түбән Кама ш.,<br>Тынычлык проспекты, 60 й.<br>usznizhnekamck@tatar.ru |
| Яңа Чишмә муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84348)<br>2-20-15 | 423190, Яңа Чишмә ав.,<br>Совет ур., 80 й.<br>Usz.Novoshesh@tatar.ru |
| Нурлат муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84345)<br>2-06-62<br>2-06-55<br>2-39-88 | 423040, Нурлат ш.,<br>Мәктәп ур., 8 й.<br>Usz.Nurlat@tatar.ru |
| Питрәч муниципаль районында социаль яклау | (84367)<br>3-06-68 | 422770, Питрәч ав.,<br>Совет ур., 20 й. |

| | | |
|---|---|---|
| бүлеге | 3-06-72 | Usz.Pitriash@tatar.ru |
| Балык Бистәсе муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84361)<br>2-11-57<br>2-39-62 | 422650, Балык бистәсе ав., Завод ур., 6а й.<br>Usz.R-sloboda@tatar.ru |
| Саба муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84362)<br>2-34-37 | 422060, Байлар Сабасы ш.т.б., Тукай ур., 87 й.<br>Usz.Saby@tatar.ru |
| Сарман муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85559)<br>2-45-72<br>2-49-87 | 423350, Сарман ав., Куйбышев ур., 36 й.<br>Usz.Sarmanovo@tatar.ru |
| Спас муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84347)<br>3-08-81<br>3-00-00<br>3-08-98 | 422840, Болгар ш., Хирург Шеронов ур., 13 й.<br>Usz.Bolgar@tatar.ru |
| Тәтеш муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84373)<br>2-62-31 | 422370, Тәтеш, Ленин ур., 114 й.<br>Usz.Tetyushi@tatar.ru |
| Тукай муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (8552)<br>70-00-57 | 423807, Чаллы ш., М.Җәлил проспекты, 46 й.<br>Usz.Tukaev@tatar.ru |
| Теләче муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84360)<br>2-13-41 | 422080, Теләче ав., Большая Нагорная ур., 5 й.<br>Usz.Tulachi@tatar.ru |
| Чирмешән муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84396)<br>2-57-05<br>2-50-94 | 423100, Чирмешән ав., Гагарин ур., 7 й.<br>Usz.Cheremshan@tatar.ru |
| Чистай муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (84342)<br>5-55-73<br>5-11-50 | 422980, Чистай ш., Урицкий ур., 45 й.<br>Usz.Chistopol@tatar.ru |
| Ютазы муниципаль районында социаль яклау бүлеге | (85593)<br>2-21-43<br>2-82-91<br>2-84-41 | 423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин ур., 105/1 й.<br>Usz.Utazy@tatar.ru |
| Казан. ш. Авиатөзелеш районы социаль яклау бүлеге | 571-58-00 | 420036 Казан ш., имирязев ур., 8 й.<br>Usz.Avia@tatar.ru |
| Казан. ш. Вахитов районы социаль яклау бүлеге | 238-10-55 | 420043 Казан ш., Вишневский ур., 10 й.Usz.Vahit@tatar.ru |
| Казан. ш. Киров районы социаль яклау бүлеге | 554-47-80 | 420102 Казан ш., Г.Баруди ур., 5 й.<br>Usz. Kirov@tatar.ru |
| Казан. ш. Мәскәү районы социаль яклау бүлеге | 544-89-94 | 420095 Казан ш., Блюхер ур., 81а й<br>Usz.Moskov@tatar.ru |
| Казан. ш. Яңа Савин районы социаль яклау бүлеге | 523-75-82 | 420044 Казан ш., Ямашев пр., 37 й<br>Usz.Novosavin@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Казан. ш. Идел буе районы социаль яклау бүлеге | 224-04-20 | 420059 Казан ш., Р. Зорге ур., 39 й. Usz.Priv@tatar.ru |
| Казан. ш. Совет районы социаль яклау бүлеге | 273-18-06 | 420037 Казан ш., Г.Кутуй ур., 33 й. Usz.SovOR@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-02 | mtsz@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чаралары методологиясе бүлеге начальнигы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Күрсәтелә торган социаль ярдәм чараларына функциональ аудит бүлеге начальнигы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru |

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Социаль үсеш идарәсе начальнигы | 264-77-29 | pisma@tatar.ru |

".

**Министр** **Э.А.Зарипова**